ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«СТАРОКУВАКСКОЕ
СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»
ЛЕНИНОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«ИСКЕ КУАК
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

19 ноябрь 2020 ел

№ 20

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Иске Куак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2018 елның 31 июлендәге 10 номерлы карары белән расланган адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

РФ Хөкүмәтенең «Адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 4 сентябрендәге 1355 номерлы карары нигезендә, Лениногорск муниципаль районы «Иске Куак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Лениногорск муниципаль районы «Иске Куак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2018 елның 31 июлендәге 10 номерлы карары белән расланган адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1. 2.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 19.11.2014 ел, №1221 карары белән расланган адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару кагыйдәләренең 20 пунктында каралган карарлар вәкаләтле органнар тарафыннан кабул ителгән документларга түбәндәгеләр кирә:»;

2. 2.6 пунктны түбәндәге эчтәлекле 10 абзац белән тулыландырырга:
«3 пунктта күрсәтелгән документ мөрәҗәгать итүченең (мөрәҗәгать итүче вәкиленең) электрон имзасы белән раслана, аның төре «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында" Федераль законның 21_1 статьясындагы 2 өлеше нигезендә билгеләнә»;

3. 1.5 пунктының 8 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«адресация объектының идентификация элементлары» - җир участоклары номерлары, башка адресация объектларының типлары һәм номерлары".

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы Иске Куак авылы, Заварыкин урамы, 36, Зеленая урамы, 7 нче йорт буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында “Авыл җирлекләре” бүлегендә (leninogorsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Иске Куак авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы И.Н. Сушкова